**«Нәүрүз»**
**Халыкара театраль белем бирү фестиваль-форумы**

# НИГЕЗЛӘМӘ

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә «Нәүрүз» Халыкара театраль белем бирү фестиваль-форумының (алга таба - Форум) максатларын, бурычларын, вакытын һәм үткәрү тәртибен билгели.

1.2. Форумны гамәлгә куючы - Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы (алга таба – Гамәлгә куючы).

1.3. Форумны оештыручы - Дәүләт бюджет учреждениесе «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры» (алга таба – Оештыручы).

1.4. Форум Партнерлары:

1.4.1. «Россия Федерациясе Театр эшлеклеләре берлеге (Бөтенроссия театр җәмгыяте)» Гомумроссия иҗтимагый оешмасы;

1.4.2. «Россия Федерациясе Театр эшлеклеләре берлеге (Бөтенроссия театр җәмгыяте)» Гомумроссия иҗтимагый оешма бүлеге - «Татарстан Республикасы Театр эшлеклеләре берлеге» (алга таба – ТРның Театр эшлеклеләре берлеге);

1.4.3. Дәүләт һөнәри белем бирү оешмасы, яисә театр сәнгате өлкәсендә өстәмә һөнәри белем бирү программалары нигезендә мәгариф эшчәнлеге алып баручы дәүләт учреждениесе (алга таба - Учреждение);

1.5. Форумның үткәрелү вакыты, темасы, белем бирү юнәлешләре, үткәрү һәм финанслау тәртибе, форумда катнашу кагыйдәләре Оештыручы тарафыннан билгеләнә һәм әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән максат һәм бурычлар кысаларында Гамәлгә куючы белән килешенә. Алга таба Форумны Оештыручы Әмере белән раслана.

## II. Форумның максатлары, бурычлары һәм үткәрү тәртибе

2.1. Форумның максатлары:

- Россия Федерациясендә һәм аннан читтә яшәүче төрки халыкларның театр мәдәниятләрен үзара баету һәм иҗади элемтәләрне ныгыту;

- Көнчыгыш һәм Көнбатыш мәдәниятләре диалогында театрларның эстетик дәрәҗәсен һәм куелыш культурасын күтәрү;

- һөнәри аралашу һәм иптәшләрчә мөнәсәбәтләр, уртак иҗади проектлар булдыру өчен шартлар тудыру;

- театрларның үзара элемтәләрен үстерү һәм ныгыту, аларны халыкара театр эшчәнлегенә якынайту.

2.2. Форумның бурычлары:

- театраль белем бирү хәрәкәтендә катнашучылар даирәсен киңәйтү;

- театр сәнгатенең заманча чаралары белән танышу һәм аларны театрлар эшчәнлегенә кертү;

- театр эшлеклеләрен заманча театр технологияләренә өйрәтү;

- актерлык уенының башкару культурасын үстерү, өстенлек итүче милли принципларын ачыклау һәм камилләштерү;

- актерларның теоретик базасын баету;

- төрле халыклар вәкилләре арасында иҗади хезмәттәшлек һәм форум кысаларында театраль лаборатория проектлары булдыру;

- милли драматургиянең иҗади үсешен һәм актуальлеген күтәрү;

- милли театраль тәнкыйтьне, журналистиканы һәм PR-технологияләрне үстерү;

- театр продуктларын халыкка җиткерү өлкәсендә алдынгы технологияләргә өйрәтү; менеджмент һәм маркетинг, реклама тактикасы һәм стратегиясе өлкәләрендә тәҗрибә уртаклашу.

2.3. Форумның тематик юнәлешләре:

- актерлык сәнгате: актерлык осталыгы буенча белем бирү программалары, тренинглар; актерлык техникаларын өйрәнү; пластика һәм хореография буенча тренинглар; курчак театры актерлары өчен лабораторияләр;

- режиссерлык сәнгате: драма һәм курчак театры режиссурасы буенча әйдәп баручы осталарның лаборатор-гамәли дәресләре; режиссер-педагогларның теоретик чыгышлары; түгәрәк өстәлләр;

- хәзерге заман драматургиясе: драматургия буенча семинарлар һәм белем бирү программалары; семинар кысаларында пьесалар иҗат итү, уку һәм фикер алышу, иң яхшы әсәрләр буенча мини-спектакльләр кую; балалар драматургиясе блогы;

- сценография һәм куелыш технологияләре: сәхнәләштерү процессының актуаль технологияләрен, 3D-технологияләр, scene-дизайн технологияләрен өйрәнү; спектакльнең сәнгати образын иҗат итү буенча лекцияләр һәм семинарлар;

- театр тәнкыйте һәм театрның әдәби бүлеге эшчәнлеге: театр тәнкыйте буенча семинарлар; спектакльләр карау һәм алар турында фикер алышу; театр рецензияләре язу һәм фикер алышу; театр коллективларын массакүләм мәгълүмат чараларында таныту буенча белем бирү (әдәби бүлек мөдирләре һәм PR-менеджерлар өчен);

- театр менеджменты, PR – технологияләр һәм театр сәнгате өлкәсендә законнар: театр продуктын тәкъдим итү өлкәсендә алдынгы технологияләргә өйрәтүче семинарлар.

## III. Форумны Оештыручының вәкаләтләре

3.1. Форумны әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру мәсьәләләрен хәл итү өчен Оештыручы киләсе Форум алдыннан елның 1 октябренә кадәр Дирекция составын формалаштыра һәм Беркетмә рәвешендә раслый.

3.2. Оештыручы Нигезләмәнең 1.4.3. пункты нигезендә Учреждениене билгели һәм үзенең карарын Беркетмә рәвешендә раслый.

3.3. Оештыручы, Гамәлгә куючы белән килешеп, Форумның Педагогик составын Форум алдыннан елның 1 декабренә кадәр формалаштыра һәм үзенең карарын Беркетмә рәвешендә раслый.

## IV. Форум Дирекциясенең вәкаләтләре

4.1. Форум Дирекциясе форум чараларын оештыру һәм үткәрү өчен җаваплы.

4.2. Дирекция Форумның программасы турында актуаль мәгълүматны Оештыручының рәсми сайтында (kamalteatr.ru) урнаштыра.

4.3. Дирекция теркәлү башлану турында игълан итә һәм әлеге Нигезләмәнең 2.3. пункты нигезендә гаризалар кабул итү һәм сайлап алу эшләрен башкара.

4.4. Дирекция Форум дәвамында Оештыручы мәйданчыгында спектакльләр күрсәтү оештыра.

5.5. Дирекциянең хокуклары:

- Оештыручы һәм Гамәлгә куючы белән килешеп, Форумны үткәрү вакытын һәм урынын үзгәртү. Бу турыда барлык кызыксынган затларга алдан хәбәр итә һәм Оештыручының рәсми сайтында (kamalteatr.ru) мәгълүмат урнаштыра;

- Форумның программасына төзәтмәләр кертү.

## V. Форумны үткәрү тәртибе

5.1. Форумда оффлайн (турыдан-туры катнашу) һәм онлайн (мәгълүмати, компьютер һәм челтәрле технологияләр кулланып, дистанцион катнашу) форматында катнашырга мөмкин.

5.2. Форумда катнашу кагыйдәләре, гаризалар кабул итү вакыты һәм форум чараларын үткәрү даталары турында мәгълүмат киләсе Форум алдыннан елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча Оештыручының рәсми сайтында (kamalteatr.ru) урнаштырыла.

5.3. Форум турында мәгълүмат алу өчен Дирекциянең актуаль элемтәләре Оештыручының рәсми сайтында (kamalteatr.ru/projects) урнаштырыла.

5.4. Форум нәтиҗәләре буенча Форумның фото-видео һәм презентация материалларын саклау, туплау, куллану һәм анализлау өчен электрон архив формалаштырыла. Архив Оештыручыда саклана.

## VI. Форумда катнашучылар һәм катнашу шартлары

6.1. Форумда катнашучылар:

- театр һөнәрләре вәкилләре, театр дисциплиналары укытучылары, театр югары һәм урта һөнәри уку йортлары студентлары, һәвәскәр театр коллективларында катнашучылар, Россия Федерациясеннән, БДБ илләреннән һәм чит илләрдән театр сәнгате өлкәсендә эшчәнлек алып баручы белгечләр.

6.2. Форумда катнашу форматын әлеге Нигезләмәнең 5.1. пункт нигезендә катнашучы мөстәкыйль билгели.

6.3. Оештыручының рәсми сайтында теркәлгәндә (kamalteatr.ru/projects) катнашучы шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык бирә. Катнашучы шәхси мәгълүматларын эшкәртүдән баш тарткан очракта гариза каралмый.

6.4. Катнашучылар санын һәм сайлап алу критерийларын Форумның һәр тематик юнәлеше педагогы билгели.

6.5. Форумда офлайн форматта катнашучы яшәү, туклану, форумны үткәрү шәһәренә/шәһәреннән кадәр булган юл һәм трансфер белән бәйле чыгымнарны мөстәкыйль түли. Моннан тыш Оештыручының рәсми сайтында заявкасы расланганнан соң оештыру взносын түли.

6.6. Форумда онлайн форматта катнашучы оештыру взносын Оештыручының рәсми сайтында заявкасы расланганнан соң түли.

6.7. Оештыручы, Гамәлгә куючы белән килешеп, сайлап алу узган катнашучылар белән форумда катнашуның оештыру һәм финанс шартлары теркәлгән Килешү төзи.

6.8. Сайлап алу узган офлайн форматта катнашучы Форумга килгәч теркәлү уза һәм катнашучы статусын раслаучы, форум программасында каралган тематик юнәлеш буенча чараларда катнашу хокукын бирүче тиешле категорияле бейдж ала.

6.9. Сайлап алу узган онлайн форматта катнашучы үз тематик юнәлеше буенча Форумның онлайн программасында каралган барлык чараларына керү мөмкинлеге ала (сылтама шәхси кабинетта).

6.10. Форум тәмамланганнан соң һәр катнашучы әлеге Нигезләмәнең 1.4.3. пункты нигезендә дәүләт үрнәгендәге сертификат (таныклык) ала.

6.11. Форумда катнашучылар форум дәвамында күрсәтелгән спектакльләргә бушлай керү хокукына ия.

## VII. Форум кунаклары

7.1. Форум кунагы булырга мөмкин:

7.1.1. Форум кысаларында спектакль күрсәтү өчен махсус чакырылган театр коллективы;

7.1.2. ЮНЕСКО каршындагы Халыкара театр институты вәкилләре;

7.1.3. «Нәүрүз» театраль белем бирү форумына ярдәм күрсәтүче рәсми делегацияләр әгъзалары, күренекле театр эшлеклеләре;

7.1.4. Россия Федерациясеннән һәм БДБ илләреннән театр сәнгатенең төрле өлкәләре буенча экспертлар.

7.2. Форум кунаклары Форум дәвамында күрсәтелгән спектакльләргә бушлай керү хокукына ия.

## VIII. Форум педагоглары

8.1. Театр педагогикасы өлкәсендә актив эш алып барган һәм үзенчәлекле укыту методикасына ия булган Форумның тематик өлкәләре буенча белгеч яки әлеге тармакның күренекле вәкиле Форум педагогы була ала.

8.2. Форум педагогы, Дирекция белән килешеп, катнашучыларны сайлап алу критерийларын, аларның санын һәм үз тематик юнәлеше буенча төркем дәресләренең расписаниесен (әлеге Нигезләмәнең 2.3. пункты нигезендә) билгели.

8.3. Форум педагоглары Форум дәвамында күрсәтелгән спектакльләргә бушлай керү хокукына ия.

## IX. Форумны массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту

9.1. Форумга әзерлекне, аның барышын һәм нәтиҗәләрен яктырту өчен Дирекция тарафыннан форум башланганчы бер ай кала Матбугат хезмәте оештырыла һәм Беркетмә рәвешендә раслана.

90.2. Форум дәвамында Матбугат хезмәте:

- Форум кысаларында узачак чараларга анонс ясый;
- ММЧ вәкилләрен һәм блогерларны аккредитацияли;

- матбугат конференцияләре, педагоглар, катнашучылар һәм кунаклар белән түгәрәк өстәлләр оештыра;

- Форум чараларында журналистлар һәм корреспондентларның катнашуын тәэмин итә;

- Форум нәтиҗәләре буенча пресс-отчет әзерли.

## X. Финанслау тәртибе

10.1. Форум Гамәлгә куючының, оештыручының һәм Форумда катнашучыларның оештыру кертемнәре хисабына финанслана.

10.2. Финанс чаралары, Гамәлгә куючы белән килешеп, Оештыручы карары нигезендә, Форумны әзерләүгә, үткәрүгә тотыла.

10.3. Оештыручы педагогларга Форум кысаларында хезмәт күрсәткән өчен гонорар түли.

10.4. Оештыручы педагогларның һәм кунакларның Форумны уздыру шәһәренә кадәр бару һәм кире кайту, кунакханәгә/кунакханәдән трансфер, яшәү һәм туклану белән бәйле чыгымнарны түли.

10.5. Оештыручы БДБ илләреннән килгән педагогларга һәм кунакларга Россия Федерациясе территориясенә керү өчен кирәкле виза һәм башка документларны рәсмиләштерү, шулай ук Форумны уздыру шәһәренә кадәр бару һәм кире кайту, кунакханәгә/кунакханәдән трансфер, яшәү һәм туклану белән бәйле чыгымнарны түли.

10.6. Оештыручы, әлеге Нигезләмәнең 7.1.1. пункты нигезендә, Форум кунагына гонорар һәм декорацияләрне транспортировкалау белән бәйле чыгымнарны (яки сәхнә бизәлешен ясау чыгымнарын) түли.